РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

Ленина ул., д. 46, с. Тюлячи, 422080

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

Ленин ур., 46 нчы йорт, Теләче авылы, 422080

тел. (факс): (843) 602-11-89, E-mail: telache@tatar.ru, http://tulachi.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 22 «17» мая 2019г.

Муниципаль хезмәт стажын билгеләүбуенча комиссия турындагы нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 2007 елның 02 мартындагы 25 санлы Федераль законга, 2013 елның 25 июнендәге 50 санлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә нигезләнеп, Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт стажын билгеләү өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. Расларга:

1.1. Кушымта № 1 нигезендә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия турында Нигезләмәне.

1.2. Кушымта № 2 нигезендә муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия составын.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 18 февралендәге «Теләче муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча бердәм комиссия төзү турында»гы 11 санлы карарын көчен югалткан дип табарга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе И. В. Мөбиновка йөкләргә

И.Ф. Зарипов

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башлыгының
2019 елның 17 май 22 санлы
карарына кушымта № 1

## Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия турында Нигезләмә

### 1. Гомуми Нигезләмәләр

1.1. Муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча комиссия (алга таба - Комиссия) муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү билгеләү, тиешле елларны эшләгән өчен ел саен бирелә торган өстәмә түләүле ялның дәвамлылыгын билгеләү белән бәйле мәсьәләләрне карау максатыннан, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен пенсия алу хокукы барлыкка килгән очракта муниципаль хезмәт стажын билгеләү өчен оештырыла.

1.2. Комиссия бердәм була һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының барлык муниципаль хезмәткәрләренең дә муниципаль хезмәт стажын билгеләү мәсьәләләрен карый.

1.3. Комиссия үз эшенлә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституцион законнарга, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, муниципаль хокукый актларга һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү тәртибе 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25 санлы Федераль законның 25 статьясы, Татарстан Республикасы Муниципаль хезмәт турындагы кодексының 30 статьясы һәм Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 04 апрелендәге 199 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәнең 28 статьясы белән билгеләнә.

### 2. Комиссиянең бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычы булып Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) муниципаль хезмәт стажын исәпләү мәсьәләләрендә гамәлдәге законнарны саклауны тәэмин итү тора.

2.2. Комиссия муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына өстәмә түләү алуга, тиешле елларны эшләгән өчен еллык түләүле өстәмә ялның дәвамлылыгын билгеләүгә хокук бирүче муниципаль хезмәт стажын һәм муниципаль хезмәткәрдә тиешле елларны эшләгән өчен пенсия алу хокукы туганда муниципаль хезмәт стажын билгели.

2.3. Куелган бурычларны үтәү өчен Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара; 2.3.1. Муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажын билгели

2.3.2. Муниципаль хезмәт стажын раслаучы (расламаучы) тәкъдим ителгән документларны карый һәм анализлый.

2.3.3. Хезмәткәрнең муниципаль хезмәте стажын билгеләү бедән бәйле мәсьәләләр буенча аңлатма алу максатында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы Хезмәт һәм социаль яклау министрлыкларына мөрәҗәгатьләр җибәрү эшен оештыра.

2.3.4. Комиссия үз компетенциясе чикләрендә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә муниципаль хезмәт стажын исәпләү һәм билгеләү белән бәйле бәхәсле мәсьәләләрне карый һәм хәл итә.

2.4. Комиссия үзенә йөкләнгән функцияләрне үтәү максатларында комиссия утырышына гариза белән мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәткәрләрне, кирәк булган очракта, аларның җитәкчеләрен, профсоюз органнары вәкилләрен, экспертларны һәм белгечләрне чакырырга мөмкин.

2.5. Комиссия, муниципаль хезмәткәр гаризасы буенча, муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт стажына муниципаль хезмәт вазыйфасын алмаштыру буенча вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле тәҗрибә һәм белемнәр кирәк булган хезмәт эшчәнлегенең башка чорларын да кертү мөмкинлеге турындагы мәсьәләләрне карап, карар кабул итәргә хокуклы.

## 3. Комиссия утырышын үткәрү өчен нигез

3.1. Комиссия утырышын үткәрүгә нигез булып тора:

- кадрлар хезмәте хезмәткәренең муниципаль хезмәткәрнең тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләүләрне исәпләү, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затларга ел саен түләүле өстәмә ял бирү өчен муниципаль хезмәткәрнең стажын билгеләү кирәклеге турында хәбәр итүе;
- муниципаль хезмәткәрнең яллаучы (эш бирүче) вәкиле исеменә хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе белән муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча бирелгән гаризасы;

## 4. Комиссия эшчәнлеген оештыру

4.1. Комиссия рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары составында формалаша.

4.2. Комиссиянең төп эш формасы булып утырышлар уздыру тора.

4.3. Комиссия утырышы өч айга бер тапкырдан да ким уздырылмый, һәм анда аның әгъзалары санынның өчтән икесеннән дә ким булмаган өлеше катнашса, ул тулы хокуклы санала.

4.4. Комиссия әгъзалары утырышта каралган мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукка ия.

4.5. Комиссия утырышында катнашкан комиссия әгъзалары комиссия эше барышында үзләренә билгеле булган мәгълүматларны таратырга хокуклы түгел.

4.6. Комиссия әгъзаларының, утырыш көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карап тикшерүгә бәйле рәвештә, мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу ихтималы булганда, алар утырыш башланганчы бу хакта белдерергә тиеш. Бу очракта комиссиянең ул әгъзасы әлеге мәсьәләләрне карауда катнашмый.

4.7. Комиссия рәисе:

- Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә һәм аның карарларының үтәлешенә гомуми контрольлек итә;

- Комиссия эшен оештыра, Комиссия тарафыннан вакытында һәм объектив карарлар кабул ителүен контрольдә тота;

- муниципаль хезмәт стажы исәпләү белән бәйле башка вәкаләтләрне башкара.

Комиссия рәисе булмаганда, аның вәкаләтләрен рәис урынбасары башкара.

4.8. Комиссия секретаре комиссия эшен оештыра:

- Комиссия утырышына кирәкле материаллар әзерли;

- Комиссия әгъзаларына булачак утырыш турында хәбәр итә һәм аларга утырыш башланырга өч көн кала өйрәнер өчен материалларны бирә;

- үз компетенциясендә булган башка оештыру-техник функцияләрне башкара.

4.9. Комиссия утырышының барышы беркетмәдә күрсәтелә.

4.10. Муниципаль хезмәт стажын исәпләү, чакырылыш буенча гражданнарның хәрби хезмәттә булган вакытын (хәрби хезмәтнең бер көне ике эш көненә санала) исәпкә алмыйча, календарь тәртиптә башкарыла. Муниципаль хезмәт стажын санаганда хезмәт (эшләү) чоры гомумиләштерелә.

4.11. Муниципаль хезмәт стажын раслаучы төп документ булып билгеле үрнәктәге хезмәт кенәгәсе тора.

4.12. Муниципаль хезмәт стажын исәпләп чыгарганда исәпкә алына торган хезмәт кенәгәсендәге язулар хезмәт кенәгәсенә кертелгән көнгә гамәлдә булган хезмәт законнары нигезендә рәсмиләштерелергә тиеш. Хезмәт кенәгәсендә муниципаль хезмәт стажына кертелә торган хезмәт (эш) чорларын раслау өчен нигез булып торган дөрес булмаган яки төгәл булмаган мәгълүматлар булган очракта, аларга хезмәт кенәгәсенә федераль законнарда каралган тәртиптә үзгәртүләр кертелә.

4.13. Хезмәт кенәгәсендә муниципаль хезмәт стажын раслаучы язма булмаган очракта, әлеге стаж хезмәт (эшнең) чорларында вазыйфаларга билгеләнгәнне һәм азат ителгәнне раслаучы документлар күчермәләре белән бирелгән белешмәләр нигезендә расланa.

4.14. Хәрби хезмәт, аңа тиң башка хезмәт үтү чорлары, шулай ук салым полициясе федераль органнары, таможня органнары хезмәткәрләренең хезмәт узу чорлары хәрби билетлар, хәрби комиссариатлар, хәрби бүлекләр, архив учредениеләре белешмәләре, хезмәт кенәгәсендәге язулар, хезмәт дәфтәре белән раслана ала.

4.15. Кирәкле очракларда муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 29 статьясында каралган вазыйфаларда хезмәт (эш) чорларын раслау өчен хокукый актларның күчермәләре яисә вазыйфага билгеләү яки азат итү турында алардан өземтә бирелергә мөмкин.

4.16. Комиссия карары Комиссия әгъзалары утырышында катнашкан күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, комиссия әгъзасы үз фикерен язма рәвештә белдерергә хокуклы, ул утырыш беркетмәсенә теркәлә.

4.17. Беркетмә утырышта катнашкан Комиссия рәисе, сәркатибе һәм барлык әгъзалары тарафыннан имзалана.

4.18. Карала торган мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен тәкъдим ителгән документларның җитәрлек булмавы сәбәпле, комиссия объектив карар кабул итү максатларында, җитеп бетмәгән мәгълүматлар алуга кадәр мәсьәләне карауны кичектерә.

4.19. Беркетмәләр, шулай ук муниципаль хезмәт стажын исәпләү өчен нигез булып торучы документлар сәркатиптә саклана.

4.20. Комиссия карарлары эшкә алучы (эш бирүче) тарафыннан тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә түләү билгеләү, тиешле елларны эшләгән өчен еллык өстәмә ялның дәвамлылыгын билгеләү, хезмәттәге югары казанышлар өчен кызыксындыру күләмен билгеләү турында боерык чыгару өчен нигез булып тора.

## 5. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. Комиссия компетенциясендәге бәхәсләр гамәлдәге законнар билгеләгән тәртиптә карала.

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башлыгының
2019 елның 17 май 22 санлы
карарына кушымта № 2

Муниципаль хезмәт стажын билгеләү буенча Комиссия составы

Комиссия рәисе:

Мөбинов И.В. – Теләче муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе.

Комиссия рәисе урынбасары:

Нурмөхәмәтов А.Ә. – район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Комиссия сәркатибе:

Закирова Г.И. – район Башкарма комитетының кадрлар белән эшләү һәм муниципаль хезмәт секторы мөдире.

Комиссия әгъзалары:

Емельянов Ю.И. – район Башкарма комитетының юридик бүлек начальнигы;

Яруллин Р.Н. – район Советының оештыру бүлеге начальнигы;

Мөбәрәкова В.Т. – район Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге начальнигы;

Гарифуллина Р.З. – район Башкарма комитетының архив бүлеге начальнигы.